СОВЕТ МАЙНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МАЙНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

Юг.Тат.Майна ав.

10.08.2022

№ 28

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 2004 елның 29 декабрендәге 190 – ФЗ номерлы законның 31 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пунктына таянып,

**Майна авыл җирлеге карар итте:**

1.«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» Көрнәле авыл җирлеге Советының 02.07.2013 ел, № 75 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Территориаль зона **Ж1 – шәхси торак төзелеше зонасы,** җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның **түбәндәге төп төрләре** белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен; торак төзелеше; шәхси торак төзелеше өчен; блокланган торак төзелеше; күчмә торак; урта катлы торак төзелеше; автотранспортны саклау; үз ихтыяҗлары өчен гаражлар урнаштыру; элемтә хезмәте күрсәтү; көнкүреш хезмәте күрсәтү; сәламәтлек саклау; эшмәкәрлек; спорт; яшелчәчелек алып бару; бакчачылык алып бару.

1.2. Территориаль зона **ОД1 - күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона,** җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның **түбәндәге төп төрләре** белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; питомниклар; автотранспортны саклау; капиталь төзелеш объектларыннан

җәмәгатьчелек тарафыннан файдалану; коммуналь хезмәт күрсәтү; коммуналь хезмәтләр күрсәтү; коммуналь хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүче оешмаларның административ биналары; социаль хезмәт күрсәтү;социаль хезмәт күрсәтү йортлары; халыкка социаль ярдәм күрсәтү; элемтә хезмәте күрсәтү; тулай тораклар; көнкүреш хезмәте күрсәтү; сәламәтлекне саклау; мәгариф һәм агарту; мәдәни үсеш; фәнни эшчәнлекне тәэмин итү; эшмәкәрлек; эшлекле идарә; сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре,сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслар); базарлар; кибетләр;банк һәм иминият эшчәнлеге; җәмәгать туклануы; кунакханә хезмәте; күңел ачу; күңел ачу чаралары; хезмәт күрсәтүчеләрнең гаражлары; автомобиль юу; автомобильләрне ремонтлау; спорт; элемтә; фәнни-җитештерү эшчәнлеге.

1.3. Территориаль зона **СХ1 – авыл хуҗалыгы җирләре зонасы** җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның **түбәндәге төп төрләре** белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; үсемлекчелек; бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү; яшелчәчелек; тонизацияли торган, дару, чәчәк культуралары үстерү; бакчачылык; йөзем үстерү; җитен һәм киндер үстерү; терлекчелек; эре терлекчелек; җәнлекчелек; кошчылык; дуңгызчылык; умартачылык; балыкчылык; авыл хуҗалыгын фәнни яктан тәэмин итү; авыл хуҗалыгы продукциясен саклау һәм эшкәртү; кыр кишәрлекләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару; питомниклар; авыл хуҗалыгы җитештерүен тәэмин итү; печән чабу; авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү; эчке тәртипне тәэмин итү; яшелчәчелек алып бару; бакчачылык алып бару.

1.4. Территориаль зона **СХ2 – авыл хуҗалыгы предприятиеләрен һәм корылмаларын урнаштыру зонасы** җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның **түбәндәге төп төрләре** белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; үсемлекчелек; бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү; яшелчәчелек; тонизацияли торган, дару, чәчәк культуралары үстерү; бакчачылык; йөзем үстерү; җитен һәм киндер үстерү; терлекчелек; эре терлекчелек; җәнлекчелек; кошчылык; дуңгызчылык; умартачылык; балыкчылык; авыл хуҗалыгын фәнни яктан тәэмин итү; авыл хуҗалыгы продукциясен саклау һәм эшкәртү; кыр кишәрлекләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару; питомниклар; авыл хуҗалыгы җитештерүен тәэмин итү; печән чабу; авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү; эчке тәртипне тәэмин итү; яшелчәчелек алып бару; бакчачылык алып бару.

2.Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы

Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://alekseevskiy.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.
4. Карар халыкка рәсми рәвештә җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Майна авыл җирлеге Башлыгы**
**Совет Рәисе** **А.С. Ларионов**